РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.06.2024 № 465-п

«2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы» муниципаль программасын раслау турында «22.02.2024 елның 22 февралендәге 161-п номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән расланган «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы» муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның 1 нче кушымтасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И. И. Кутдусовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазифаларын башкаручы,
Башкарма комитет Җитәкчесенең
икътисад буенча – Саба муниципаль районы
икътисад бүлеге башлыгы М. М. Баһманов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 10 июнендәге 465-п номерлы карарына кушымта

«2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы» муниципаль программасына 1 нче кушымта

## «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү программасы» муниципаль программасының максатчан индикаторлары, күрсәткечләре

| № т/б | Күрсәткечләрнең, чараларның аталышы | Җаваплы башкаручы, башкаручылар | Максатчан индикаторлар | | | Чыгымнар мең сум, еллар | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| 1 | КУЭ вәкилләре өчен семинарлар, күргәзмәләр һәм конференцияләр үткәрү, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының кече һәм урта эшкуарлыгын үстерүгә зур өлеш керткән эшкуарларны бүләкләү | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инвестицияләр һәм эшкуарлыкка ярдәм бүлеге | 10 | 10 | 10 | 100,000 | 0,000 | 0,000 |